## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**6 декабрь, 2024 ел** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Күкшел авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Күкшел авылында гражданнар җыены **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2025 елда Кукмара муниципаль районының Күкшел авыл җирлеге Күкшел авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш түшәлгән юлларны төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру, юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка төр эшләр); (юлларны карап тоту Күкшел авылында урам-юл челтәре, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу, проект-смета документациясе); (автомобиль күперен төзү һәм ремонтлау, торба сатып алу, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру); (Күкшел авылының урам-юл челтәрләренә су үткәргеч торба урнаштыру, технадзор сатып алу, ташу, урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су җыю башняларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, койма сатып алу һәм урнаштыру, артезиан скважиналары өчен насослар, материаллар сатып алу, проект-смета

үткәргеч торба урнаштыру, технадзор сатып алу, ташу, урнаштыру, проект-смета

документациясен эшләү, технадзорны гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне карап тоту буенча башка төр эшләр);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантын, комплектлаучы детальләрне, инвентарьларны сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү);
- ремонт, киртәләр кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (материал, инвентарь урнаштыру, сатып алу, агач кисү, киртәләрне ремонтлау, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка төр эшләр, проект-смета документлары һәм технадзорны гамәлгә ашыру);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Күкшел авылы территориясен төзекләндерү, территорияне төзекләндерүнең башка төрләре, спорт мәйданчыгын төзекләндерү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазландыру, инвентарь, җайланмалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, спорт мәйданчыгын төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка төр эшләр).

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Күкшел авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Хәмидуллин